**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АЛАН-БӘКСӘР**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур.,19

**СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

Тел./факс: +7(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**КАРАР**
**7 июль 2023 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 79**

**Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларның хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" 2018 елның 30 апрелендә кабул ителгән 122 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына нигезләнеп, Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 30.04.2018 ел, № 122 карарына (Советның 20.09.2018 ел, № 145, 16.01.2019 ел, № 159, 30.09.2020 № 6 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 1 нче пунктта 15 нче абзацны гамәлдән чыгарырга;
- “Дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлар белән эшләү өчен айлык процент өстәмәсе күләме һәм муниципаль хезмәткәрнең вазифа хезмәт хакы күләме” дигән 12 нче кушымтаны гамәлдән чыгарырга;
- “Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә еллар буе хезмәт иткән өчен пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган бүләкләүне гамәлгә ашыру тәртибе турында нигезләмә” дигән 13 нче кушымтаны 12 нче кушымта дип санарга.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгару һәм авыл җирлегендә урнашкан рәсми мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина